**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт.
Тел.3-44-56

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА СТАРОКУРМАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

**КАРАР**
«07» ноябрь 2024 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
№ 2

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең Иске Кормаш торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Иске Кормаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Иске Кормаш авыл җирлеге Башлыгы **карар бирә:**

1. 2024 елның 18 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Шәбезбаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. 2024 елның 18 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Кыр-Каентүбә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

3. 2024 елның 19 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Яңа Балтач торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

4. 2024 елның 19 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Иске Балтач торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

5. 2024 елның 20 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Иске Кормаш торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә..

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итүне тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү)тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.
2. Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру

өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуын карап тоту һәм ремонтлау);

3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (җирлек чигенә Стелла урнаштыру һәм аңа табличкалар әзерләү)
4. Һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (обелиск әзерләү һәм урнаштыру, обелиск территориясен төзекләндерү);
5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урам юлларын карап тоту һәм ремонтлау);
6. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалау(зиратларны карап тоту).

**“ӘЙЕ”** **“ЮК”**

7. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә:

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Шабизбаш авылы, Үзәк урамы, 21 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Кыр-Каентүбә авылы, Үзәк урамы, 38 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Яңа Балтач авылы, Үзәк урамы, 2 нче йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Балтач авылы, Үзәк урамы, 29 нчы йорт;

Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Кормаш авылы, Үзәк урамы, 26 нчы йорт.

8. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны Иске Кормаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

10. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Д.Р.Вәлиева